

Авыл йозен кешеләр билгели. Авылнын топ байлыгы - анын тырыш, унган, эчкерсез кешеләре. Зубово-Поляна районындагы кечкенә оч татар авылын кешеләре яшәтә. Татар Лундан (Иске ил диләр авыл турында) авылы халкы борынгыдан эш соючән һәм һонәрле булулары белән аерылып торган. Бvген без бу авылда туып vскән, анда гомер кичерә торган Рафик Гельман улы Утимишев турында сойләрбез.
Эш шунда ки, Горенка мәктәбе сайтында (ВКонтакте) укытучылар коллективы исеменнән шундый язу бар: “Хормәтле Рафик Гельман улы!
Туган конегез белән котлыйбыз! Сезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек телибез. Ата-анагызга олы хормәт һәм рәхмәт!       Сез интеллигент, әдәпле, тыйнак кеше; туган проблемаларны чишәргә булышасыз, һәрвакыт ярдәм итәсез. Сезнен унай сыйфатларыгызны чиксез санап чыга алабыз, әмма, бәлки, аларнын ин моһиме - якыннарыгызны яратуыгыздыр.
Бәхетле булыгыз! Сезне мәхәббәт, игътибар чолгап алсын. Елмаю һәм шатлык очен һәрвакыт сәбәп булсын! Жаныгызда һәм гаиләгездә гармония, бетмәс энергия, тормыш союченлек, унышлар, игелек һәм хыялларыгызнын тормышка ашыруын телибез!”



Авылны яшәртер очен, нәкъ шундый кешеләр булуы шатландыра.
Авылны саклап калу, халкына булышу, анын элеккеге данын югалтмау очен жан атып йори Рафик Гельман улы Утимишев. Әти-әнисе - Абдулла улы Гельман белән Низам кызы Мәсума да шушы авылда туып vскәннәр, гомер буе шунда яшәп, шунда хезмәт иткәннәр. Балаларын да кешелекле, хезмәт соючән итеп vстергәннәр. Шуларнын берсе, алда әйткәнебезчә, vз жиренен чын патриоты Рафик Гыйльман улы.
Ул кечкенәдән бер генә авыр эштән дә курыкмый vсә. Авыл баласы булгач, гаиләсе белән бергә колхозда кара козгә кадәр бәрәнге (бу авылда жир алмасы диләр) алырга, чогендер эшкәртергә, ындыр табагында эшләргә, печән әзерләргә дә туры килә ана. Топ белемне Татар Лака авылында, ә урта белемне Шеренгуши мәктәбендә ала. Аннары, профессия нечкәлекләренә тошенер очен, Зубово Поляна профессиналь училищесын (СПТУ) тәмамлый. Эшли башлагач, vзенен классташы, унган һәм тырыш Фәрит кызы Наимә белән матур гына тормыш корып жибәрәләр. Фәрит кызы Нәимә белеме буенча Питердә (Санкт-Петербург) бухгалтер-экономист техникумын тәмам-лаган.



Бvген каенатасы белән каенанасын хөрмәтләп карый. Яшь булуына карамастан, әти-әнисе тосле тырыш, булдыклы кызлары Диляра да Санкт-Петербугта хезмәт итә.
Рафик Гыйльман улы 28 еллап “Родина” колхозларында хезмәт итә, заманалар vзгәрә башлагач колхозлар бетә һәм “Вектор” җәмгыятчелегендә тырышып эшли; “Бекон”га бармый инде. Үз тракторы белән халыкка, акчага булса да, иртә таннан карангы тонгә кадәр я жир сорә, я печән чаба, шул арада агрегатын тиз генә алмаштырып бәрәнге араларын ера – һәм башка, һәм башка авыл жирендә чvпләп бетерә алмаслык эшләрне башкара. Әйтеп китәргә кирәк, кечкенә авылларда бу эшләрне башкаручы кеше таба алмаска да момкин, ә язма героебыз бер кешегә дә ялындырып тормыйча башкара, шуна рәхмәтләрнен ин ялкынлысын оч татар милли авыл якташлары, хәтта Пичпанда авыл халкы да әйтә.
Тынгысыз жанлы, туганнарынын, туган жиренен, бvген кырыкка якын кеше яшәгән авылдашларынын кадерен белеп яшәvче Рафик Гельман улы Утимишевка ныклы сәламәтлек, эшендә тагын да зуррак унышлар, гаилә бәхете, жан тынычлыгы теләгән Горенка мәктәбе директорына, коллективы белән, зур рәхмәтләрен тормыш иптәше Нәимә Фәрит кызы белдерә. Әйтеп китим, Рафик Гельман улы Утимишев мәктәпкә дә, кирәк чакта ярдәм итә - жир эшләрен башкара. Авыл хужалыгы хезмәткәрләре конендә авыл жирлекләрендә армый-талмый эшләvчеләр турында язу тагы бер тапкыр алар хезмәтен хөрмәтләv, олылау була.



Шәхси тормышы да кызыклы-интересный анын. Гасырлардан - гасырларга кvчеп килгән милли тәрбия алганнар. Гаиләдә алар ике малай - абыйлы-энеле Рафик белән Али дус-тату vсәләр. Бvген гаиләләре дә кардәшләр генә тvгел, ә чын дуслар да. “Бекон” җәмгыятчелеге эшмәкәре Гельман улы Али һәм Горенка мәктәбе башлангыч сыйныф укытучысы Ринат кызы Галина ике ул (Динар, Радик) тәрбиялиләр. Ойләре дә кара-каршы гына. Әти-әнисе Абдулла улы Гельман белән Низам кызы Мәсуманы да бергә хөрмәтлиләр. Аларнын бvләсе әйберләре юк - бар нәрсәләре уртак, хәтта мал-туарлары да. Жиде ел бергә торгач, каршы гына йорт салып торуга карамастан, топ йорттагы абзарда сыерларын, сарыклары-куйларын, кош-кортларын бергәләп карап vстерәләр. Хәтта ике йортка бер бакчалары да. Быел бар яшелчәләрдән мул уныш алганнар. Жир алмаларынын эреләре vзләренә ашарга калдыралар, ә вакларын хайваннарга ашаталар.
Ирнен бәхетле булуы хатынынннан тора, диләр. Һәрхәлдә, Утимишевлар гаиләсендә дә шулай. Фәрит кызы Нәимә белән аралашканда бу ханымнын ни дәрәжәдә акыллы, сабыр, булдыклы хатын-кыз булуына соклану хисләре уянды. Әле ул Рафик ирен тәмле-тәмле татар халкына хас ашамлыклар белән дә сыйлый. Менә шушындый кvркәм кешеләр яши Татар Лунданында. Авылны эшсояр унганнар яшәтә дә инде ул.

**Наилә НАСЫРОВА**